# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2023 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Татар Шуганы торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

**13 октбрь 2022 ел** **№2**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Татар Шуганы авыл җирлеге Татар Шуганы торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2023 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар өчен 200 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Татар Шуганы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:
-җәйге чорда Татар Шуганы авылында территорияне чабу;
- Татар Шуганы авылында «Халыкара өлкәннәр көне», «Сабантуй» бәйрәм чараларын үткәрүне оештыру;
- трактор йөртүче хезмәте өчен түләү;
- Татар Шуганы авылы Сөембикә урамында юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш салу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү) ;
- МТЗ-82.1 тракторы очен КУН-10 сатып алу;.

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Татар Шуганы авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Татар Шуганы авыл җирлеге башлыгы М.Ш.Хәертдинов
(имза) (имза расшифровкасы)